| | | |
|---|---|---|
| ИНСПЕКЦИЯ<br>ГОСУДАРСТВЕННОГО<br>СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ<br>КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |

ПРИКАЗ БОЕРЫК

___28.02.2024_____ Казан шәһәре № ___22______

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2016 елның 15 февралендәге 12 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында

БОЕРЫК БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2016 елның 15 февралендәге 12 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 21.02.2018 ел, №19, 30.09.2022 ел, №111, 22.02.2023 ел, №13, 08.09.2023 ел, №77, 22.12.2023 ел, №144 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлегендә:

1.3 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре, Инспекция) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу турында чикләмәләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда, башка федераль законнарда коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларның үтәлешен (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу) тәэмин итүдә;»;

III бүлектә:

3.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга комачаулаучы, аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килүе турында хәбәр итүе.»;

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән белдерүләр коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган вазыйфаи зат тарафыннан карала, ул белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмә әзерли.»;

3.4.2 пунктта «3.1 пунктның «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән белдерү» сүзләрен «3.1 пунктның «б» пунктчасындагы бишенче абзацында һәм «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләр» сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.3 пунктта:

«а» пунктчасында 3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен 3.1 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә белдерүләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18, 3.18.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр.»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планга кертелгән) утырышында карала.»;

3.8 пунктта «3.1 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «3.1 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

3.8.1 пунктның «а» пунктчасында «3.1 пунктның» б « пунктчасы белән» сүзләрен «3.1 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 3.18.1 пункт белән тулыландырырга:

«3.18.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

3.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча һәм, моңа нигезләр булган очракта, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11-3.15.1, 3.17-3.18.1 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.».

Җитәкче В.Р.Нәҗмиев